12+

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы   30 сентябрь, 2016 ел   № 5 (150)




Лилия Туктарова фотосы

# Тавыш бир!

Яраткан уку йортыбыз, шәһәребезне дәүләт банкноталарында күрү өчен барлык студентларны һәм хезмәткәрләрне тавыш бирүдә актив катнашырга чакырабыз! Нәтиҗәләр 7 нче октябрьдә билгеле булачак. Моның өчен «Твоя-Россия.рф» сайтына кереп, кәрәзле телефон яки «Facebook», «ВКонтакте», «Одноклассники» социаль челтәрләре аша теркәлергә һәм тавыш бирүдә катнашырга кирәк. КФУ өчен тавыш бир, тарихка кереп кал!

## ЯҢА КИЛЕШҮЛӘР

КФУ вәкилләре ректор **Илшат Гафуров** җитәкчелегендә Алманиядә Rohde & Schwarz компаниясе белән эшлекле очрашуда булып кайттылар. Эш барышында «КФУ-Ростех» үзәгенең киләчәге турында фикерләштеләр. Ике атнадан соң КФУга Алмания делегациясе килүе көтелә.

## МЕГАГРАНТ

КФУда узган «Киләчәк фәне» II Халыкара фәнни конференциясе кысаларында А.Бутлеров исемендәге Химия институты РФ Хөкүмәтенең мегагрантына ия булды. Аның бәясе – 90 миллион. Мегагрантны алман галиме **Кристоф Шик** алачак. Ул КФУда зуртизлекле калориметрия лабораториясен булдырачак. Башлангыч этапларда К.Шик лабораториясе коллективының яртысын аспирантлар һәм студентлар тәшкил итәчәк.

## УКЫТУЧЫЛАР КОНГРЕССЫ

4-8 октябрь көннәрендә КФУда V «Рус теле һәм әдәбияты укытучыларының Россия җәмгыяте» конгрессы үтәчәк. Көн кадагында халыкның уку һәм сөйләм культурасын, филологик грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрү, рус филологиясе өлкәсенә караган уку программаларын һәм мәгариф стандартларын камилләштерү, балаларны һәм яшьләрне рус телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә мотивацияләү мәсьәләләре каралачак.

# КФУда ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ ЯҢӘДӘН АЧЫЛДЫ

**Илсөяр НУРЕТДИНОВА**

КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫНДА БУШЛАЙ ТАТАР ТЕЛЕ КУРСЛАРЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ. АЛАР ӨЧ АЙ ДӘВАМ ИТӘЧӘК.



Автор фотосы

Оештыручылар әйтүенчә, татар теле курсларына карата кызыксыну кимеми, ел саен татар телен өйрәнергә теләүчеләр табылып тора. Быел, мәсәлән, курсларга 800ләп кеше язылган. Бу узган елгы саннардан күбрәк.

Әлеге курсларның житәкчесе **Кадрия Фәтхуллова** әйтүенчә, язылучыларның төп максаты – татар телен аралашу-аңлашу чарасы буларак үзләштерү, сөйләм күнекмәләренә ия булу, татар дөньясы турында мәгълүмат алу. Курсларга йөрүчеләрне бер максат берләштерсә дә, башка сәбәпләр дә бар: кемнеңдер күршеләре белән татарча аралашасы килә, кемгәдер эш урынында хезмәттәшләре белән татарча сөйләшергә туры килә, ә өченчеләре исә, гаилә кору белән бәйләп, яңа туганнар белән аралашу өчен татарча белү кирәк дип аңлата. Кадрия ханым аеруча горурланып сөйли торган укучыларының берсе – япон егете **Юто Хишияма**. Халыкара татар теле олимпиадасында катнашканнан соң, Татарстан Президенты **Рөстәм Миңнеханов** Ютога Казан университеты магистратурасында бушлай уку сертификаты тапшырган булган. Ул ике ел татар филологиясе бүлегендә укыган. Хәзер Юто Хишияма Токио университетында татар телен укытырга хыяллана.

Бу курслар «Татарстанда дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында оештырыла. Анда төрле милләт вәкилләре, төрле яшьтәге, төрле һөнәр ияләре укый. Урыслар гына түгел, ана телен белмәгән татарлар да күп. Моннан тыш Русия ислам институтында да бушлай татар телен өйрәнү курслары эшли. Түләп укыта торган фирмалар да бар.

Америкалы **Келли Алумс** шундыйларның берсендә белем алган. Тик ул, бу курсларда да йөреп, татар телен камилләштерергә тели.

**Жанболат Жәтибай** Казахстанның Актүбә каласында туып үскән. Бүген Казанда укый. «Сез Казахстанда булсагыз, казах телен өйрәнер идегез. Мин дә Татарстанда татар телен өйрәнү форсатын кулланырга тиеш», – ди. **Альфредо Усен Рефана Ндреманина-зафу** Мадагаскарда туып үскән. «Мин Татарстанда яшим. Татар халкын тагын да якыннанрак танырга, татар егет-кызлары белән дуслашырга телим», – ди ул. Альфредо техник уку йортында (элеккеге КАИ) радиоэлектроника белгечлеге буенча белем ала. «Рәхмәт, исәнмесез кебек сүзләрне беләм. Тик бу гына җитми», – ди. Ул ислам динен кабул иткән һәм татар кызы белән гаилә коруга да каршы түгел.

Яшьләрдән тыш, курсларга пенсионерлар да йөри. Аларны, белем дәрәҗәләреннән чыгып, төрле төркемнәргә бүләләр: башлап өйрәнүчеләр, дәвам итүчеләр һәм урта дәрәҗәдә белүчеләр. Рус һәм башка милләт вәкилләре белән бергә, курсларга йөрүчеләр арасында татарлар да шактый. Аларның теләге – туган телдә тагын да камилрәк сөйләшү, татар матбугаты язмаларын аңлап уку, татарча дөрес яза алу, татар халкының милли йолаларын, гореф-гадәтләрен үзләштерү. Узган елгы курсларда Төркия, Кытай, АКШ һәм башка илләрдән килгән студентлар да татар телен яратып өйрәнгәннәр.

Курсларны уңышлы тәмамлаучылар сертификат алалар һәм, киләсе елда да татар телен өйрәнүне дәвам итүләренә өметләнеп, укытучыларына рәхмәтле булып саубуллашалар. Бирелгән белем яңа юллар ача.



# ЕРАКТАН СӘЛАМ



**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

КҮПТӘН ТҮГЕЛ ГАЗЕТАБЫЗ ПОЧТАСЫНА БИК ЕРАКТАН КЫСКА, ӘММА ЖЫЛЫ ЭЧТӘЛЕКЛЕ ХАТ КИЛЕП ТӨШТЕ. ХАТ АВТОРЫ – КАЙЧАНДЫР КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАГАН АСПИРАНТ ЛӘЙСӘН ТУКТАМЫШЕВА.

*«Мин Казан университетының Юридик факультетын тәмамладым. Шунда ук кандидатлык диссертациясе дә якладым. Тик Казанда калып эшләү планнары кисәк кенә үзгәрде, һәм мин тугыз ел элек Америкага китеп бардым. Монда, Казан университеты биргән төпле белем һәм дипломым нигезендә, Коннектикут университетына магистратурага укырга алдылар.*

*Америкада юриспруденция буенча магистратура узгач, лицензия алу өчен берничә штатта имтихан тапшыру хокукы бирделәр. Мин исә Нью-Йоркны сайладым. Хәзерге вакытта Коннектикут Университетында докторлык хезмәте язам. Казан университеты – күңелемә иң якын һәм кадерле урын. Уку йортыбыз турында иң якты истәлекләр генә саклана. Мондагы мөгаллимнәр биргән белем бөтен дөнья күләмендә ихтирамга лаек. Казан университетына булган хөрмәтем һәм рәхмәтем чиксез».*

**Фото герой архивыннан**

# КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ СӘЯХӘТ

**Лилия ӘХМӘТГАЛИЕВА**

КҮПТӘННӘН РАДИО ҺӘМ ТЕЛЕВИДЕНИЕ БЕЛӘН ЯКЫННАНРАК ТАНЫШАСЫМ КИЛӘ ИДЕ, БЕЗ ТӨРКЕМЕБЕЗ БЕЛӘН «ТАТАРСТАН» ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯСЕНӘ ЭКСКУРСИЯГӘ БАРУ БӘХЕТЕНӘ ИРЕШТЕК.

Бу гади генә җир түгел – керү өчен махсус пропусклар булырга тиеш. Кергәч, үзеңне мөһим кеше итеп хис итәсең. Экскурсияне «Татарстан» радиосы журналисты **Раил Садретдинов** үткәрде. Ул татар радиосының ничек барлыкка килүе турында сөйләде: хөкүмәт сәясәтен җиткерү өчен, 1921 елда беренче тапкыр Казанда рупордан хәбәрләр укыла. Бу яңалыкны «Известия» газетасы язып чыкканнан соң, В.И.Ленин мондый рупорларны Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә дә урнаштырырга кирәк дигән боерык бирә. Димәк, радио дәвере нәкъ менә Казаннан башлана. Шамил Усманов тырышлыгы белән 1927 елның 7 ноябрендә, бик күп кыенлыклар аша үтеп, беренче диктор Гадел Кутуйның: «Тыңлагыз, Казан сөйли!» дигән сүзләре белән «Татарстан» радиосы телгә килә. Бүген дә һәр иртәдә эфирда әлеге сүзләр яңгырый.

Беренче радио Горький паркы тирәсендә чатырда урнашкан була. Ул күп тапкыр үз урынын үзгәртә: Кәрим Тинчурин театры, Карл Маркс урамындагы милли китапханә, Кекин йорты. Бүген ул Шамил Усманов урамында.

Экскурсиябез Нәсим Акмал җитәкләгән әдәбият-сәнгать редакциясеннән башланды. Безне бик җылы каршы алдылар, кадерләп түргә утырттылар, үзләре башкарган эшләр турында сөйләделәр. Без студия белән таныштык, радиорепортаж әзерләү серләрен белдек.

«Татарстан» Дәүләт телевидениесе белән безне Екатерина Сударева таныштырды. Без өр-яңа, заманча җиһазландырылган телестудиядә булдык. Камера, утларны минут эчендә студиянең бер башыннан икенче башына күчереп була. Алып баручы урындыгында үзебезне чын алып баручы итеп хис иттек.

Яңа ачышлар, танышулар күңелдә онытылмаслык эз калдырды. Яңа җиһазлар, студияләрдән кала, мица күбрәк хезмәткәрләр ошады. Аларның үз эшләрен яратып эшләүләре, безгә игътибарлы булулары күңелләргә сары май булып ятты. Шундый җылылыкка ничек шатланмый була инде?!



Лэйлә Сабирова фотосы

• Тел сагында

# АНА ТЕЛЕНӘ МӘХӘББӘТ

**Айгөл ГӨСЕЙНОВА,** КФУ укытучысы

ЗУР ГАЛИМ, ЯЗУЧЫ, ЖУРНАЛИСТ, КҮПТӘН ТҮГЕЛ 80 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТКӘН, БЕРНИЧӘ БУЫН ШӘКЕРТЛӘРНЕҢ ОЛЫ ОСТАЗЫ ИЛДАР АБЫЙ НИЗАМОВ ТУРЫНДА ЯЗАРГА БУЛДЫМ.

Мин үземнең хөрмәтле остазым белән инде кечкенәдән үк таныш булганмын. Әле ул вакытта мин аны университет профессоры дип белми идем, хәтта журналистика өлкәсенә укырга керәчәгем дә билгеле түгел иде. Мин бары тик радиоалгычтан аның «Тел күрке – сүз» тапшыруын йотлыгып тыңлый идем. Бәлки инде шул вакытта ук ул миндә татар теленә, сөйләменә мәхәббәт уяткандыр да.

Университетта укыган вакытта, без аны олылап, яратып, якын итеп, «Абый» дип дәшә идек. Аның дәресләрендә сихерле дә, кызыклы да булган тел дөньясында сәяхәттә булып кайткан кебек иде. Төрле холыклы яшьләрдән җыелган төркем шәкертләрен журналистика белән кызыксындыра ала, телгә хөрмәт, ярату уята белә иде ул. Илдар абый күп кенә кешеләрнең алдагы тормыш юлларына маяк, дөрес юл күрсәтүче булгандыр.

Чын укытучы гади була дип әйтсәм, дөрес тә булмас кебек. Шулай да бу сүзләрдә Илдар абыйның безгә карата ачык, киң күңелле булуы, шул ук вакытта гадел дә, таләпчән дә була белүе чагылыш таба дип уйлыйм.

Аның дәресләрендә туган телгә, сөйләмгә хөрмәт беренче урында тора дип әйтү ялгыш булмас. Татар теле мәсьәләләре, фән, укыту турында булган кайбер уйланулары хакында Илдар абыйга сорау бирми калу мөмкин түгел.

**– Бүгенге тормышыбызда тел мәсьәләсе, аны укыту системасы турында фикерләрегез нинди?**

– Милләт белән телне аерырга ярамый: татар милләте, аның тарихы, киләчәге турында сөйләшәбез икән, ул телдән аерылгысыз булырга тиеш. Тел турында сүз алып барабыз икән, беренче чиратта, телнең үзен өйрәнү, икенче мәсьәлә – ул телне куллану, өченчесе – укыту мәсьәләсе булырга тиеш. Әйтик, японнар телне тел дип 5нче сыйныфтан соң өйрәнмиләр, аннары телне куллану өйрәтелә. Ә безнең 11 класска кадәр «тәмамлык», «ия» дип тукыла, югары уку йортына килгәч тә шул ук эш дәвам итә. Сөйләм, сөйләмият фәне, телне куллану – мәктәп тә, югары уку йортлары да менә нәрсә белән шөгыльләнергә тиеш.



• Фото герой архивыннан

**– Инде телдән аерылгысыз булган татар журналистикасының киләчәге нинди дип уйлыйсыз?**

– Без журналистикада европача фикерләмибез. Безнең татар журналистикасының 100 еллык үз фикерләү менталитеты бар. Ул матбугатка хәбәр чыганагы гына түгел, ә хәбәрне аңлатып җиткерү чарасы итеп тә карый. Шуның өчен бездә, хәбәр жанрларыннан тыш, аналитик, тасвирлау жанрлары да көчле. Димәк, алга таба нинди үзгәрешләр булса, шушы үзенчәлекләрне истә тотарга кирәк. Университетта югары журналистика мәктәбе ачылуы – ул әйбәт фал. Димәк, ул яңача, нинди яңалыклар кертеп эшләр кебек.

**– Сезнең кебек профессор дәрәҗәсенә ирешү өчен яшь галимнәргә әйтер сүзләрегез?**

– Максат. Максатсыз фән юк. Гомерлеккә алынган максат. Сәгатькә, көнгә, айга, елга алынган максат түгел: гомереңне шуңа бирергә кирәк. Ә моның өчен син үзеңнең сәләтеңне, тамырыңны белергә тиешсең. Булдыра аламмы мин моны, дип. Мәсәлән, ана телен тоемлау сәләте сиңа әнидән бирелмәгән икән, син журналист яки тел галиме була алмыйсың. Шушы тоемлауны син инде әнидән үк, балалар бакчасыннан, мәктәптән саклап килергә тиешсең һәм, шушы тоемлавың бар икән, аны үстерергә, тәрбияләргә кирәк. Бу инде туктаусыз уку, аралашу белән бәйле. Шундый максаты булса, яшь галим үсә, уйлана ала. Икенчесе, шушы максатның нәтиҗәләре белән кызыксынучы бармы? Өченчесе – тырышлык. Кечкенә генә уңыш та кешене үстереп җибәрә, тынычландыра. Тырышлык, тырмашу, көрәш, тартышу – шушы сәләтләр белән максатка ирешеп була. Туктамаска кирәк. Фәндә моңарчы халык, җәмгыять белмәгән якларны ачарга кирәк.

*«... Әгәр дә мөгаллим вә тәрбияче булсаң, шул рәвештә тәрбия кыл ки, ул тәрбия кылынмыш адәмең үлгәнче синең тәрбияң буенча тереклек кылырлык булсын... »*

**Каюм Насыйри**

**– Университет шәкертләренә киңәшләрегез нинди?**

– Казан университетында төрле катлам балалары укый. Мин гомерем буе күбрәк татар журналистикасы, татар әдәбиятына кызыксыну белдергән студентлар белән аралаштым. Мин, иң беренче чиратта, аларны университетка укырга керүләре белән котлыйм. Өч йөз елга якын тарихы булган университетта уку – бик зур горурлык ул. Икенчесе – татар баласы буларак, татар бүлегенә керүләре белән котлыйм. Татар теле белән кызыксынып, теләп керү – бик зур ачыш ул. Өченчесе инде, төгәл татар журналистикасы кафедрасына кереп укый алулары белән ихластан котлыйм. Бу юнәлештә укырга тели икән – яшь кешенең максаты бар дигән сүз. Максаты булган кеше алга барачак. Уңышлар барысына да!



• КФУ Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбенең татар журналистикасы кафедрасы. Лилия Туктарова фотосы.

# БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ИЛДАР АБЫЙ...

БИЛГЕЛЕ БУЛГАНЧА, ИЛДАР МӘЛИК УЛЫ НИЗАМОВ ИСЕМЕ ГАММӘВИ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫНДА БИК ЕШ ЗУРЛАП, ДАНЛАП ТЕЛГӘ АЛЫНА. АНЫҢ ТУРЫНДА ҺӘРВАКЫТ ҮРНӘК КЕШЕ БУЛАРАК ЯЗЫП ТОРАЛАР. ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАФЕДРАСЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕНЕҢ ФИКЕРЛӘРЕН БЕЛҮ КЫЗЫКЛЫ.

• **Васил Заһит улы Гарифуллин, профессор, татар журналистикасы кафедрасы мөдире:**

Ул безгә фән ягыннан гына түгел, бар яктан да үрнәк булып тора. Кафедрада бергәләп эшләргә туры килде. Аның «җимешчәнлеге», продуктивлыгы таң калдыра иде: ел саен китап чыгармыйча калганы булмады. Кафедрада эшләгәндә, хәтта елга бернечә китап чыгарганы да булды. Фәнгә бирелгәнлеге, гаиләсенә тугрылыгы, авылны, җирне, эшне яратуы белән үрнәк кеше ул. Аның бу асыл сыйфатлары эшне яратуыннан киләдер. Аның кебек булырга тырышырга кирәк яшьләргә, шул исәптән безгә дә!

• **Резеда Локман кызы Зәйни, доцент:**

Фән кешеләре көне-төне диярлек фән белән шөгыльләнсәләр генә чын профессор дәрәҗәсенә ирешә ала дип уйлыйм. Илдар абый кебек галимнәр бик аз, чөнки җәмгыять башканы таләп итә. Хәтерлим, укыган вакытта ук Илдар абый безне зур галим генә түгел, башка һөнәрләргә дә ия булган төрле яклы шәхес буларак сокландыра иде.

• **Венера Нәгыйм кызы Исмәгыйлева, татар журналистикасы кафедрасының өлкән лаборанты:**

Илдар Маликовичның, иң беренче чиратта, чын гаилә кешесе булуын әйтергә кирәктер. Ул үзенең хәләл җефетен бик хөрмәт итә, балалары, оныклары белән горурлана. Мин аны авыл җанлы кеше буларак беләм. Кичләрен мич янында яки җылы учак ягып, китап язып утырырга ярата. Аның бихисап хезмәтләре – аның иҗат җимешләре, үзе әйтмешли, «балалары». Аннары ул бик оста балыкчы да, бу эшнең барлык нечкәлекләрен, тәмен белеп шөгыльләнә.

• **Ләйлә Рәшит кызы Сабирова, доцент:**

Илдар абый Низамов дигәндә, күз алдына аның практик журналист, тел белгече, язучы, зур галим булуы килә. Таләпчән, шул ук вакытта урынлы шаян, төпле белемле, үз гыйльми принципларына тугры калып, шәкертләренә журналистика кануннарын үтемле төшендерә белүче дә ул. Туган телебез турында чынлап кайгыртучан кеше. Мин аңа бик рәхмәтле!

***P.S:*** язманың тулы вариантын **darelfonyn.kpfu.ru** да укырга мөмкин.

• ***Чакыру***




**Илдар Низамовның** парча, хатирәләре тупланган «Бөртектән – көшел» исемле яңа китабы белән танышасыгыз килсә, сезне Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында (Мөштәри урамы, 14 нче йорт) 2016 елның 10 октябрендә 17 сәгатьтә көтәбез.

# КФУ УЛ ...

Ләйлә САБИРОВА

СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫ – ТЕЛӘСӘ КЕМ ХӘТЕРЕНДӘ МӘҢГЕ САКЛАНА ТОРГАН ИСТӘЛЕКЛЕ ЕЛЛАР УЛ. КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ 2016-2017 ЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ДӨНЬЯНЫҢ ИҢ ЯХШЫ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ РЕЙТИНГЫНА ЭЛӘКТЕ. БУ РЕЙТИНГНЫ QUACQUARELLI SYMONDS (QS) БРИТАНИЯ КОНСАЛТИНГ КОМПАНИЯСЕ ТӨЗЕГӘН. TIMES HIGHER EDUCATION ХАЛЫКАРА РЕЙТИНГ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА КФУ РОССИЯНЕҢ ИҢ АЛДЫНГЫ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ АРАСЫНДА ДҮРТЕНЧЕ УРЫННЫ САКЛАП КАЛДЫ. БУ УҢАЙДАН БЕЗНЕҢ БЕРЕНЧЕ КУРС СТУДЕНТЛАРЫ ГОРУРЛЫК ХИСЕ КИЧЕРӘЛӘР МИКӘН? АЛАР ӨЧЕН КФУ НӘРСӘ УЛ?

**• Назлыгөл Мәсәлимова:**



Хыял... Мәктәп елларыннан ук сакланып килгән бер хыялым, теләгем бар иде, ул да булса, Казан федераль университетына укырга керү. Әле дә исемдә, беренче тапкыр конференциягә барган чагым. Зур мәһабәт бина, биек колонналар, гаҗәеп матур архитектуралы уку йорты мине үзенә тулысынча гашыйк итте. Шул көннән бирле нәкъ шунда укырга керү теләге белән янып яшәдем. Университет киләчәк тормыштагы мөмкинлекләргә ачкыч булып тора.Ул минем өчен уку йорты гына түгел, ә яңа дуслар, күңелле хатирәләр, хыялларны тормышка ашыру урыны да. КФУ – минем дөньям, минем киләчәгем!

**• Раилә Вәлиуллина:**



Университет – үзе бер аерым дөнья. Монда һәркем үз-үзен таба, максатына туры юл сала, хыялларын тормышка ашыра ала. Бары тик тырышлык һәм уҗәтлек кирәк. Синең нинди милләттән булуың, шушы җирлектәнме яки чит илдән (ә андый студентлар университетта бихисап) килүең мөһим түгел, монда бары да тигез, бары да тату. Бездә бер төркем эчендә дөньяның төрле почмакларыннан килгән студентларны очратырга була. Шуның өчен КФУны халыклар дуслыгы йорты дисәм дә ялгыш булмастыр. Алай гына да түгел, Казан федераль университеты – һәрберебез өчен туган өебез кебек якын, кадерле урын.

**• Айсылу Хафизова:**



Икенче курс укучысы соравыма кыска гына итеп: «КФУ ул – старт», – диде. Югары курс студентлары исә җитдирәк итеп җавап бирәләр: «КФУ минем өчен – хезмәт, төпле уку һәм зур мөмкинлекләр». Мин бу сүзләрнең барысы белән дә килешәм. КФУ ул – горурлык, төпле белем, якты киләчәк, яшьлек, онытылмаслык мизгелләр, яңа танышулар. КФУ ул – яңа көнне елмаеп каршы алыр өчен зур сәбәп. КФУ кешегә үзенең идеаль образын төзергә һәм чынга ашырырга булыша. Шуңа күрә, КФУ ул – МИН!

**• Айсылу Нигъмәтҗанова:**



Бәйгеләр, студент язлары, багышлаулар, бәйрәмнәр һәм тагын күпме исәпсез-хисапсыз ярышлар, тулай торак тормышы, автобус-троллейбуста җыйнаулашып укырга барулар – боларның барысын да Казан дәүләт университеты үз эченә туплый. КФУ минем өчен – күңелле вакыйгалар, студент тормышы. КФУ җәмгыятьтә үз урыныңны табарга ярдәм итә һәм мөстәкыйльлеккә өйрәтә.

**• Алинә Юнысова:**



Монда килгәч, әти-әниләрнең: «Бер группада укучылар тагын да кадерлерәк була», – дип әйтүләренең чыннан да дөреслеккә туры килгәнен аңлыйсың. КФУ студентлары уку йортыннан гына түгел, ә яшәү урыныннан да уңды. Универсиада авылында яшәргә кемнәр генә кызыкмый икән! Спорт белән шөгыльләнүчеләргә бигрәк тә уңайлы, чөнки якын-тирәдә бик күп спорт биналары, мәйданчыклары бар. КФУ – югары белем, якты йөзле кешеләр, яңа дуслар, иҗат, эмоцияләр ташкыны!

ӘГӘР ГОМЕРЛЕК ЮЛДАШЫ ИТЕП ЖУРНАЛИСТИКАНЫ САЙЛАМАСА, УЛ, МӨГАЕН, БИЮЧЕ БУЛЫР ИДЕ. УЛ ТИК ТОРА ТОРГАННАРДАН ТҮГЕЛ. СҮЗЕМ ЖУРНАЛИСТИКА ҺӘМ МЕДИАКОММУНИКАЦИЯЛӘР ЮГАРЫ МӘКТӘБЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ КУРС СТУДЕНТЫ, ЯШЬЛӘРНЕҢ «АЛТЫН КАЛӘМ – 2016» РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ЖУРНАЛИСТИКА БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕСЕ ИЛГИЗ ШӘКҮРОВ ТУРЫНДА.



Фото герои архивыннан

# «КҮҢЕЛ ЯТКАН ҺӨНӘР»

**Раил САДРЕТДИНОВ**

Соңгы 5 елда ул журналистика белән ныклап кызыксына башлый. «Журналистика ул – кеше күрмәгәнне күрү», – дип аңлата Илгиз. «Алтын каләм» бәйгесендә җиңүгә 5 ел дәвамында кечкенә, ләкин төпле адымнар белән килә. «Җиңү өчен талант кирәк һәм тырышлык. Ансыз бер өлкәдә дә уңышка ирешеп булмыйдыр. Уңыш сере гади: 99% тырышлык һәм 1% сәләт», – ди ул.

Журналистика белән чынлап торып «җенләнеп» китүгә радиодан ишеткән хәбәр сәбәпче була. Алла Пугачеваның үз радиосын булдыру һәм радиожурналист һөнәрен үзләштерергә хыяллануын белгәч, Илгиз дә Актанышта журналистика серләренә өйрәтә торган түгәрәккә йөри башлый. Әлеге түгәрәк җитәкчесе Лидия апа Галимова аны журналистика дигән дөньяга җитәкләп алып керә. Башта Илгиз мәктәп тормышын, имтиханнар, яшьләр, танышу кебек темаларны яктырта. Бу язмаларын «Актаныш таңнары» газетасында күтеп алсалар, соңрак ул Актаныш радиосында «Ә син белә идеңме?», «Мәйдан», «Түребездә кунак бар», 2013 елда узган Универсиада хәбәрләреннән торган «Универсиада сулышы» тапшыруларын әзерли һәм алып бара. Шул ук вакытта, Актаныш телевидениесендә «Актанышым-мактанышым» проекты кысаларында башкалар күрсәтергә һәм сөйләргә курыккан фактлар турында юмор белән сөйли.

Иңнәрендә зур тәҗрибә багажы булган беренче курс студентыннан яхшы журналист булу серен сорашам. «Яхшы журналист булу өчен, оператив булырга, башкалар күрә алмаганны күрә белергә кирәк. Шул ук вакытта грамоталы булу мөһим. Нинди генә очракта да кешелеклелекне югалтырга ярамый», – ди ул.

Журналистика өлкәсендә кумирларым юк, дип белдерә Илгиз. «Әмма минем өчен бик якын, күпмедер мәгънәдә укытучыларым бар. Болар – үзләре дә «Алтын каләм»нән үсеп чыккан, журналистика белеме алган Фәнзилә Мостафина, Линар Закиров, Эльмира Закировалар. Алар белән һәрвакыт аралашып торабыз».

*«КФУ – ул журналистика сыман, һәрвакыт заманча, вакыт белән бергә атлый, халыкка хезмәт итә»*

Күптән түгел генә «Алтын каләм» фестивале җиңүчеләре Мәскәүдә булып кайтканнар. Алар арасында әңгәмәдәшем дә бар. «Алтын каләм»леләр башкалабызның күренекле урыннарында – Останкино манарасы, Мәскәү елгасы, Кызыл мәйданда булганнан соң, Журналистлар союзына да барганнар. «Безне Журналистлар союзы рәисе Всеволод Богданов һәм Роман Серебрин каршы алдылар. Кыска гына дусларча әңгәмә дәвамында алар безнең кем булуыбызны сораштырды, үзләренең ничек журналистикага килүе турында сөйләде. Татарстанга кайнар сәламнәрен җиткереп калдылар».

«Журналистиканы сайламасам, башка бер күңел тартмаган өлкәдә эшли алмас идем», – ди Илгиз. Алга таба ул үзен басма матбугатта сынамакчы. Бүген һөнәр сайлау алдында торучыларга киңәш итеп, ул: «Кем генә, нәрсә генә әйтмәсен, үз күңелегез яткан һөнәрне сайлагыз. Шул вакытта гына уңышка ирешә алачаксыз», – диде.

• **2016 - Россиядә кино елы**

# Үзебез төшергән кино

**Диләрә КАМАЛОВА**

КҮПТӘН ТҮГЕЛ КАЗАНЫБЫЗДА XII ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ ГӨРЛӘП УЗДЫ. БУ ЧАРАДАН ҺӘМ, ГОМУМӘН, КИНО СӘНГАТЕННӘН КФУ СТУДЕНТЛАРЫ ДА ЧИТТӘ КАЛА АЛМАДЫ. ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ КЫСАЛАРЫНДА ЭШЛӘП КИЛӘ ТОРГАН «ӘЛЛҮКИ» ӘДӘБИ ИҖАТ БЕРЛӘШМӘСЕ БЕЛӘН ҮЗ КИНОБЫЗНЫ ТӨШЕРДЕК.





Автор фотолары

Университетта игълан ителгән «Иң яхшы сценарий» конкурсы җиңүчесе 2 нче курс студенты Рүзилә Әмирова сценарие буенча кыска метражлы нәфис фильм төшерергә булдык. Минем дә әлеге фильмга үз өлешемне кертәсем килде. Камера, штатив бар, видеолар төшерү буенча тәҗрибә начар түгел, иң мөһиме – теләк! (Ә бездә ул бик көчле иде).

Гадәттә, фильм төшергәндә берничә төрле проблема килеп чыгарга мөмкин: команда, актерлар төркеме, фильм төшерү өчен җирлек һәм аппаратура табу. Соңгысы белән берниндидә тоткарлыклар булмады, уртак тырышлык белән барлык кирәкле җиһазларны үзебездә булдырдык.

«Без, без, без идек…» дип исемләнгән әлеге фильм студентлар тормышы турында иде. Шунлыктан, кино мәйданчыгы табу белән дә берниндиавырлык килеп чыкмады. Күпчелек күренешләр үзебез яши торган тулай торак – Универсиада авылында һәм университет бинасында төшерелде.

Фильмда «атказанган» актерлар – Г.Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбенең 1-2 курс студентлары төште. Һәрберсе, үз роленә кереп, аны менә дигән итеп башкарып чыкты! Шулай итеп, монысы белән дә берниндичитенлек тумады.

Фильмның техник ягы бик үк мактанырлык түгел. Тик, шуңа да карамастан, без командабыз белән бик аз вакыт эчендә зур эш башкардык. Киләчәктә, бәлки, Халыкара мөселман киносы фестивалендә дә безнең нәфис фильмнарны күрә алырсыз әле!

• **Студент колагына**



## СЕЗНЕҢ ӨЧЕН

«ДАРЕЛФӨНҮН» ГАЗЕТАСЫНА – 5 ЯШЬ! ШУЛ УҢАЙДАН КФУ ТАТАР СТУДЕНТЛАР ГАЗЕТАСЫ – «STUDENT'S BLOG» ДИГӘН ИНТЕРНЕТ-БӘЙГЕ ИГЪЛАН ИТӘ!

Уку – энә белән кое казу дип, бу эшне никадәр җитдиләндерсәләр дә, дәрестә, тулай торакта, төркемдәшләр белән булган кызыклы хәлләр мәңгегә истә кала, сагындырып искә төшә икән. Без сезне әлеге мизгелләр белән уртаклашырга чакырабыз. Моның өчен студент тормышыннан төрле кызыклы хәлләрне безгә, **darelfonun@yandex.ru** электрон почтасына, юллау да җитә. Бу бәйгедә студент елларын сагынучы өлкәнрәк яшьтәге укучыларыбыз да катнаша ала. Чөнки студент еллары – кеше гомеренең күңелле мизгелләре, яшьлек чоры ул. Искә төшер, яз, катнаш, җиң! Җиңүчеләрне төрле бүләкләр көтә! Бәйге, әлеге игълан басылып чыккан көннән алып, 15 декабрьгә кадәр үткәрелә.

12+
DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 29.09.2016. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.